**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 ноябрь № 874

г. Казань

2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында югары белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елда югары белем бирүче мәгариф оешмалары тулай торакларында студентлар яшәүгә норматив чыгымнар бер белем алучыга 1 елга 2 555 сум тәшкил итә, дип билгеләргә.

2. 2016 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының аспирантурасында (адъюнктурасында) фәнни-педагогик кадрларны әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар күләменә карата төзәтү коэффициентларын.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2015 елга Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары мөлкәтен карап тоту һәм югары белем бирү һәм югары уку йортларын тәмамлаганнан соң һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 810 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары мөлкәтен карап тоту һәм югары белем бирү һәм югары уку йортларын тәмамлаганнан соң һөнәр белеме

бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 810 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 23 июнь, 458 нче.

4. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\874.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 ноябрь, 874 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының
югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыруга
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Әзерлек (белгеч-лек) юнәлеше коды | Әзерлек (белгечлек) юнәлеше | Бер кешегә югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, 1 елга сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | әзерлек программалары буенча белем бирүнең көндезге формасы | | | әзерлек программалары буенча читтән торып белем бирү формасы | | әзерлек программалары буенча белем бирүнең кичке формасы | |
| | | специа-литет | бакалаври-ат | магистра-тура | специа-литет | бакалаври-ат | специа-литет | бакалаври-ат |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 021700 | Филология | 37088 | | | | | | |
| 030100 | Информатика | 35307 | | | | | | |
| 031100 | Мәктәпкәчә белем бирү педагогикасы һәм мето-дикасы | | | | 7238 | | | |
| 061000 | Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә | 38907 | 38244 | | 7526 | 6956 | | |
| 260501 | Җәмәгать туклануы продукциясе технологиясе | 45798 | | | | | | |
| 521000 | Психология | | 38172 | | | | | |
| 552800 | Информатика һәм хисаплау техникасы | | 40254 | | | | | |
| 351101 | Товарлар белеме һәм | 45097 | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | товарлар экспертизасы | | | | | | | |
| 260800 | Продукция техноло-гиясе һәм җәмәгать тукlануын оештыру | | 41687 | | | 8635 | | |
| 040400 | Социаль эш | | | | | 9731 | | |
| 080100 | Икътисад | | 38015 | | | 9363 | | |
| 050400 | Психология-педагогика белеме бирү | | | | | 7677 | | |
| 013100 | Экология һәм табигатьтән файдалану | | 35994 | | | | | |
| 080104 | Хезмәт икътисады | 37771 | | | 10706 | | | |
| 080502 | Нефть һәм газ сәнәгате предприятиесендә икътисад һәм идарә итү | 42107 | | | 7048 | | | |
| 130503 | Нефть һәм газ ятмаларыннан казылмалар чыгару һәм аларны эксплуатацияләү | 47206 | | | 8820 | | 18614 | |
| 130501 | Газ-нефть үткәргечләрне һәм газ-нефть саклагычларны проектлау, төзү һәм эксплуатацияләү | 46963 | | | 8876 | | | |
| 130504 | Нефть һәм газ скважи-наларын бораулау | 47003 | | | 8318 | | 18779 | |
| 130602 | Нефть һәм газ скважиналары машиналары һәм җиһазлары | 50626 | | | | | 20298 | |
| 140104 | Сәнәгать җылылык энергетикасы | 45618 | | | 8991 | | | |
| 140604 | Сәнәгать җайланмаларының һәм технология комплекс-ларының электр приводы һәм | 46378 | | | | | 17834 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | автоматикасы | | | | | | | |
| 151001 | Машина төзелеше техноло-гиясе | 47494 | | | | | 20543 | |
| 220301 | Технология процессларын һәм җитештерүләрен авто-матлаштыру | 53355 | 50763 | | | | 20779 | |
| 080200 | Менеджмент | | 36976 | | | 7842 | | |
| 100100 | Сервис | | 37311 | | | | | |
| 151900 | Машина төзелеше җитеш-терүләрен конструкторлык-технологик тәэмин итү | | 48535 | | | 8364 | | 18964 |
| 131000 | Нефть-газ эше | | 46336 | | | 7946 | | 18213 |
| 140100 | Җылылык энергетикасы һәм җылылык техникасы | | 47100 | | | | | |
| 151000 | Технология машиналары һәм җиһазлары | | 48301 | | | | | |
| 351100 | Товарлар белеме | | 42373 | | | | | |
| 220400 | Техник системаларда идарә итү | | 38771 | | | | | 13231 |
| 140400 | Электр энергетикасы һәм электр техникасы | | 47995 | | | 8312 | | 18925 |
| 25.00.15 | Бораулау һәм скважи-наларны үзләштерү технологиясе | | 46336 | | | | | |
| 21.04.01 | Нефть-газ эше | | | 96637 | | | | |
| 15.04.04 | Технология процессларын һәм җитештерүләрен авто-матлаштыру | | | 94281 | | | | |
| 38.04.01 | Икътисад | | | 73016 | | | | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 ноябрь, 874 нче карары белән расланды

Югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының аспирантурасында (адъюнктурасында) фәнни-педагогик кадрларны әзерләү программаларын тормышка ашыруга

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Әзерлек (белгечлек) юнәлеше коды | Әзерлек (белгечлек) юнәлеше | Бер кешегә аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрларны әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, 1 елга сум | |
|---|---|---|---|
| | | фәннәр кандидатын әзерләү программалары буенча белем бирүнең көндезге формасы | фәннәр кандидатын әзерләү программалары буенча белемне читтән торып бирү формасы |
| 05.11.16 | Мәгълүмат-үлчәү һәм идарә итү системалары | 46465 | 16804 |
| 05.02.13 | Машиналар, агрегатлар һәм процесслар | 53139 | 15251 |
| 25.00.17 | Нефть һәм газ ятмаларыннан казылмалар чыгару һәм аларны эксплуатацияләү | 51532 | 15982 |
| 25.00.15 | Бораулау һәм скважиналарны үзләштерү технологиясе | 49836 | 14739 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 ноябрь, 874 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының югары белем бирү буенча төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар күләменә карата

**ТӨЗӘТҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ**

| Т/с | Учреждение исеме | Төзәтү коэффи-циенты |
|---|---|---|
| 1. | «Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты» дәүләт автоном югары белем бирүче мәгариф учреждениесе | 1,633651 |
| 2. | «Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты» дәүләт автоном югары белем бирүче мәгариф учреждениесе | 1,269128 |
| 3. | «Әлмәт дәүләт нефть институты» дәүләт бюджет югары белем бирүче мәгариф учреждениесе | 1,329218 |